ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

Акбаш ав. №2 1 март 2023 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләре, җирле үзидарә депутатларының, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 17 сентябрендәге «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, муниципаль хезмәткәрләргә, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларга, сайланулы вазыйфаи затларына хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында"гы 1015 санлы карары, 2018 елның 28 мартындагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына, җирле үзидарәнең сайланулы затларына үз вәкаләтләрен даими нигездә, Татарстан Республикасы контроль-хисап органнары рәисләре, муниципаль хезмәткәрләр турында"гы 182 санлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләрен, Акбаш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2018 елның 18 маендагы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, сайланулы җирле үзидарә затларының хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында"гы 10 санлы Акбаш авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1 бүлекнең 3 пунктында "унбер" сүзен «10,36» саннары белән алыштырырга;
2 бүлекнең 1 пунктында "11 163" саннарын «12 688» саннары белән алыштырырга;
2 бүлекнең 6 пунктында "бер процент» сүзен «18 процент» сүзләренә алыштырырга;
3 бүлекнең 1 пунктындагы 6 пунктчасында «бер процент» сүзләрен «18 процент» сүзләренә алыштырырга; күрсәтелгән карар нигезләмәсенә №1 кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (беркетелә).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында рәсми бастырып чыгару юлы белән түбәндәге адрес буенча игълан итәргә http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга http://jutaza.tatarstan.ru.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан бирле үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Акбаш авыл җирлеге башлыгы Л.Р.Синәгатуллина

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советы карары белән расланган Җирле үзидарә депутатларының, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарәнең Акбаш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек башлыкларын, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын акчалата бүләкләү күләме

| Вазыйфаларның исемнәре | Акчалата бүләкләү үлчәмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә оешкан авыл һәм шәһәр җирлекләрендә |
| | 12 төркем |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 17390 |